**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
23.10.2020

**КАРАР**
№ 532

**2021 елга Тәтеш муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирүче туган якны өйрәнү-туризм, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, фәнни-табигый, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында " 2009 ел, 31 декабрь, 939 нчы карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга расларга:

- "Тәтеш муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туган якны өйрәнү-туризм, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, фәнни-табигый, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмәне (кушымта) ;

- Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга туган якны өйрәнү-туризм, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, фәнни-табигый, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф

оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын.

2.Тәтеш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**4.**Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Тәтеш муниципаль районы**

**Башкарма комитеты**

**Җитәкчесе** **А.Б.Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 23 октябрендәге
532 номерлы карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туган якны өйрәнү-туризм, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, фәнни-табигый, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләренең һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләренең балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программалары юнәлешләре | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга 1 елга сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Беренче уку елы | Икенче уку елы | Өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Әнгати-эстетик | Шәһәр җире | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| Физкультура-спорт | Шәһәр җире | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| Техник иҗат | Шәһәр җире | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| Туризм һәм туган якны өйрәнү | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| Экологик-биологик | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| Хәрби-патриотик | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| Иҗтимагый-педагогик | Шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| Социаль-икътисади | Шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| Фәнни-табигый | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |